ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
_04.07.2025___

**К А Р А Р**
№ 561_

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елда Биектау муниципаль районы белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар тукландыруны оештыру турында» 2025 елның 24 гыйнварындагы 97 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 16 сентябрендәге 789 номерлы карары белән расланган 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны ризык белән тәэмин итү бәясе нормативына үзгәреш кертү турында» 2025 елның 27 маендагы 362 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елда Биектау муниципаль районы белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар тукландыруны оештыру турында» 2025 елның 24 гыйнварындагы 97 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның икенче абзацында «9,60 сум» санын «10,30 сум»га алмаштырырга һәм «2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны ризык белән тәэмин итү бәясе нормативын» кертергә.

1.2. 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны ризык белән тәэмин итү бәясе нормативын «2025 елда Биектау муниципаль районы белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар тукландыруны оештыру турында» 2025 елның 24 гыйнварындагы 97 номерлы карарын түбәндәге эчтәлекле 2 нче кушымта белән тулыландырып расларга:

«2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 24 гыйнварындагы 97 номерлы карарына

**2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны ризык белән тәэмин итү бәясе нормативы**

| Норматив исеме | Укыту чорында бер укучыга көнгә бәяләр нормативы, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны ризык белән тәэмин итү бәясе нормативы | 10,3 | 10,0 | 10,4 |

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин